ВӘГАЗЬ
Исраф кылмаучы фәкыйрьләнмәс
→ 6 БИТ

КОРЪӘН ҺӘМ ФӘН
«Бүгенге фән 1400 елга артта калган»
→ 7 БИТ

САБЫЙГА
Пәйгамбәребезнең дөньяга килүе
→ 9 БИТ

ӘДӘП-ӘХЛАК
Балтач районында әхлак фәне укытылуга 25 ел
→ 10–11 БИТ

**ИЮНЬ, 2023**
№ 06 (335)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

ЗӨЛКАГЪДӘ–ЗӨЛХИҖҖӘ, 1444

# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



Фотоның авторы: FabrikaPhoto / elements.envato.com

**Кеше үзенең яшәеш дәверендә матди керемгә, малга, байлыкка мохтаҗ, чөнки Адәм баласына тормышын камил итеп алып барыр өчен, ризык, кием, торак һәм күп кенә тормыш хаҗәтләре, матди чыгымнар таләп итәлә. Ислам дине матди байлыкка, акчага карата нинди мөнәсәбәттә соң? Шушы мәсьәләдә без – мөселманнар нәрсәләрне исәптә тотарга тиеш?**

ДӘВАМЫ → 6 НЧЫ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

# МИЛЛИ ТӘРБИЯНЕҢ МӨҺИМЛЕГЕ

Ислам галимнәре халык яшәсен өчен, дүрт әйбер кирәк дип тапкан. Әгәр шуларны сакламасак, халык яшәүдән туктый, юкка чыга, дигән.

### БЕРЕНЧЕСЕ – ДИННЕ САКЛАРГА КИРӘК

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дин кануннары буенча яшәгән кешене кояшка карап барган кеше кебек, дип әйткән. Кояшка карап барсак, күләгә артыбыздан бара, беркая китми. Кеше тормышын Аллаһы кушканча көйли икән, дөнья да беркая китми, чөнки ана карынында 4 ай да, 10 көн булганда барысы да язылган инде. Шул язганны хәләл юл белән дә, харам юл белән дә табып була. Мәсьәлә шунда гына. Ә инде, динне ташлап, дөнья кусак, кояшка арканы куеп барган кебек булабыз. Кояшка арканы куеп барсак, күләгәбез алдан бара, аны куып җитеп булмый.

Локман Хәким: «Кеше – көймә, акча – су», – дип әйткән. Көймә сусыз йөзә алмаган кебек, акчасы да кирәк. Әмма шул су көймә эченә керсә, ни булыр? Әлбәттә, көймә батар. Сүз дә юк, эшләргә, кәсеп итәргә кирәк, әмма акча күңелдә түгел, ә кесәдә булырга тиеш. Әгәр кешенең күңелен дөнья тулысынча биләп алган икән, аның укыганы өч тиенгә дә тормый.

Диннән башка нәфесне җиңеп булмый. Нәфесне җиңә торган бердәнбер корал – ул дин. Нәфесне рәткә китермичә, без дә тәртипкә килә алмыйбыз.

Шиһабетдин Мәрҗани: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый: ул милли тел, милли кием, милли гореф-гадәт», – дип әйткән. Бүгенге көндә кайберәүләр моны инкяр итә, тел нәрсәгә ул, диләр. Ана телен югалткан кеше Төркиягә барса, кайсы телдә сөйләшә? Әйе, кайсы милләт кешесе булуга карамастан, төрекчә сөйләшә. Гарәбстанга барса да шулай ук. Ә бездә кеше телен югалтса, кайсы телдә сөйләшәчәк? Аның ничә проценты мөселман булачак?

Милли кием мәсьәләсе дә шулай ук. Рус милләте арасында яшәгәч, әбиләребез яулыгын да үзенчә бәйләгән, бабайларыбыз түбәтәйдән йөргән. Элек татар әбисен, бабасын урамда очраткач, аның татар милләтеннән булуын аңлап булган, кызганычка, хәзер алай түгел. Бер язучы кеше дә бу хакта язган иде: элек Казан урамы буйлап татар карчыгы барса, ул икенче бер татар карчыгын танып алып, исәнләшеп, сөйләшә башларлар иде. Татар карты да үз милләт кешесен танып алыр иде. Бүген яшьләр арасында да бер-берсен күрү, танышу өчен бу мәсьәләдә аерма юк, шуңа да катнаш никахлар да күп. Кызганычка, милләтебезнең 40%тан артыгы катнаш никахта. Бүген ашауда да, киемдә дә, гадәттә дә аерма юк. Бу да безнең фаҗигабез, болар динне, милләтне алга җибәрә торган гамәлләр түгел.

Милли гореф. Бүген кайбер яшьләр: «Зиратка барып Коръән укымагыз, өчесе, җидесе, кырыгын үткәрмәгез», – дип әйтә. Минем бер табынга туры килгәнем бар, болар хәмер эчеп утыра. Нишлисез, дигән соравыма: «Нурулланың 40ын искә алабыз», – диделәр. Әгәр без мәҗлес ашларын тыеп, аны үткәрмәсәк, халык аны шул рәвешле үзләренчә үткәрә башлый. Безнең балалар да барысын да телевизордан күреп үсә бит. Әгәр без аларны: «Зиратта Коръән укымагыз», – дип үстерсәк, бала зиратка баргач, башка җирдә күргәнен эшли: йә чыбыкка-чыбык бәйләп, бастырып куя, йә ризык, йә ясалма чәчәк куеп китә. Ә без аны, Коръән укы, дип өйрәтсәк, ул зиратта берничә аять укыр иде. Каш ясыйк дип, күз чыгармыйк. Шушы нечкәлекләрне исәптә тотып, хикмәт белән эш итик.

### ИКЕНЧЕ ӘЙБЕР – УЛ ҖАН

Бүген без җанны саклыйбызмы? Никах укыганда барыбыз да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Никахланыгыз, күбәегез, Кыямәт көнендә башка өммәтләр каршында өммәтемнең күплеге белән горурланырмын», – дигән хәдисен сөйлибез. Күз алдына китерегез, Россиядә көн саен 11 000 баланың җаны өзелә икән. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә үтерелгән кешеләрне үтерүчеләр янына китерер һәм үтерүчеләрдән: «Ник үтердең?» – дип соралгач, алар: «Ул миңа янады, мине куркытты», – кебек сүзләр белән җавап бирер. Шул вакытта дөньяга туарга тиеш булып та, тумый калган сабыйлар китерелер һәм Аллаһы Тәгалә: «Боларның гаебе нинди иде?» – дип сорар икән. Бу сорауларга күп кешенең җавап тотасы бар бит.

Кызганычка, кешенең күңелендә Аллаһы Тәгаләгә карата мәхәббәт булмаса, ул корыган агач кебек була. Ул агач көн үткән саен череп, юкка чыга бара. Безнең дә күңелләрдә Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт булмаса, әти-әнине түгел, хәтта баланы да ярата алмыйбыз. Баланы мәшәкать дип күрәбез, безнең эшләребезгә, үсешебезгә комачаулый, дип уйлыйбыз. Ничек кенә яшәсәк тә, бу дөньяны калдырып китәсе була, ул байлыкны кемгә дип җыйган булабыз соң?!

Җанны саклау дигәндә, беренчесе, бала алып кайту булса, икенчесе, харам ризыктан тыелырга кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бер сум харамнан тыелу, мең сум садака бирүдән хәерлерәк», – дигән. Харам ризык кешенең калебен каралта, ихтыяр көчен бетерә. Баланың хәләл ризыкны «Бисмилләһи» сүзләре әйтеп, уң кул белән ашавы кирәк. Әйе, бала сул кул белән эш эшләргә дә, язарга да мөмкин, әмма ашарга уң кулы белән генә тиеш.

Дин булсын, алга барсын өчен, өммәт һәм тынычлык кирәк. Бүгенге көндә динне алга җибәрәбез дип, әллә нинди хикмәтле китаплар, программалар әзерләнә, әмма аны укытырга кешесе юк. Телевизордан авылның бер имамын күрсәтәләр, аннан сорау алалар: менә мәчеткә йөрүче балалар саны кимегән, диләр. Әмма, җәмәгать, авылда балалар бакчалары, мәктәпләр ябыла, чөнки йөрергә, укырга балалар юк. Мәктәпкә йөрергә балалар булмагач, ничек мәчеткә йөрүче бала булсын инде?! Хатын-кызлар бәби алып кайтмагач, мәчеткә йөрүче балалар саны кими инде, билгеле. Балалар бакчалары, мәктәпләр ябыла дип, хөкүмәтне сүгәбез. Әмма авылда 50-60 бала булса, ул балалар бакчалары, мәктәпләр ябылмас иде. Шуңа да милләт булсын өчен, динне, җанны сакларга кирәк. Әгәр уйлап карасак, харам ашау да, җан өзелү дә, катнаш никах та динсезлек бәласе ул.

## ӨЧЕНЧЕСЕ – НӘСЕЛНЕ САКЛАРГА КИРӘК

Без үзебезнең нәсел шәҗәрәсен, аның казанышларын, күренекле шәхесләрен белергә, балаларыбызны да үз нәселе белән горурланырга өйрәтергә тиешбез. Нәселең белән горурланыр өчен, тарихыңны өйрәнергә, милләтеңнең үткәнен белергә, үзеңнең милли каһарманнарыңны белергә кирәк.

Милли хәзинәбезне саклап йөртүче милләт аналары буласы кызларыбызның юкка чыгуы – ягъни башка кавемне тәрбияләве – бүгенге чорыбызның иң зур фаҗигасе. Дөрес нәтиҗә ясыйк, алга таба бу фаҗигале юлдан баруыбызны туктатыйк. Туган телебездә фикерлик, татарча сөйләшик, үзебезчә сөйләшә торган балалар үстереп калдырыйк. Шулай булганда гына милләтебезнең киләчәге өметле булыр.

Кайсы гына милләт вәкиленнән: «Нәселеңдә иң беренче кеше кем булган?» – дип сорасак, ул Адәм галәйһиссәламне атар. Гарәпчә язылыштагы «адәм» сүзенең беренче хәрефе – намазда басып торучы, икенче хәрефе – рөкүгъта торучы, өченче хәрефе сәҗдә кылучы булып күренә. Бу хәрәкәтләр – намазда, димәк, без – намаз укучылар нәселеннән.

Нәселне кайгырту, саклау дигән сүз – матди яктан тәэмин итү генә түгел ул. Намаз укучылар нәселеннән булгач, үзебездән соң намаз укучылар калдыру да. Уңны сулдан аера башлагач, баланы намазга өйрәтә башлау лязем (тиешле). Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Балаларыгызга җиде яшьтән үк намазга басарга боерыгыз, 10 яшьтә әлеге боерыгыгызны үтәмәсәләр, аларны җәзага тартыгыз һәм 10 яшьтә намаз өйрәнмәсә, тәрбия камчысы өстен булсын», – дигән (Имам Әбү Давыдның хәдисләр җыентыгыннан).

## ДҮРТЕНЧЕСЕ, МАЛНЫ САКЛАУ

Малны таба да, саклый да белергә тиешбез. Бүген без, кызганычка, балаларыбызны һөнәр, хезмәт сөя торган итеп үстермибез. Барысына да укып, эшләмичә генә акча ала торган урын эзлибез. Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне җәннәттән җиргә төшергәч, иң беренче итеп, игенчелек һөнәрен өйрәтә, чөнки өстәмә продукция бирә торган бердәнбер әйбер – ул җир. Иң яхшы заводка бер килограмм тимер керсә, ничә килограмм кадак чыга? Бер килограммнан да азрак кадак чыга, әмма җиргә ярты бәрәңге салсаң, иң начар уңдырышлы елны да ике-өч бәрәңге үсеп чыга. Шуңа да гомер буе кеше җир дип тырышкан. Бүген безнең илдә җирнең кадере бармы? Кызганычка, юк! Без әнине дә, җирне дә кадерләргә өйрәтмибез.

Коръәни Кәримдә:

*«Һичшиксез, Без кешене михнәт эчендә яраттык», – диелгән.*

*«Әл-Бәләд / Шәһәр», 90:4*

Без бүгенге көндә балаларыбызны эшләтмичә, уңайлы шартларда яшәтергә тырышабыз, аларны шәһәргә куабыз, без күргәнне күрмәсеннәр, михнәт чикмәсеннәр дибез. Әгәр тимерне утка тыгып, суга салып чыныктырмасаң, аннан эш коралы ясап булмый. Без дә бүген балаларыбызны тормышка әзерләмибез, намазга, уразага уятырга да, эш эшләтергә дә җәллибез. Без малны таба да, тота да белергә тиеш.

Димәк, нәсел дәвам итсен, нигезебез нык, балаларыбыз тәрбияле булсын, халык буларак югалмыйк дисәк, менә шушы дүрт әйбергә игътибар итәргә кирәк: динне саклауга – йортыбызда дин булырга тиеш; җанны саклауга – бала җаны өзелмәскә, харам кермәскә тиеш; нәселне саклауга – бала нәселен белеп, горурланып үсәргә тиеш; малны саклауга – балаларыбыз һөнәрле булып үсәргә тиеш, чөнки һөнәрле кеше беркайда да югалмый.

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга хәерле гомерләр, саулык-сәламәтлекләр бирсә иде. Раббыбыз кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә, балаларыбызның, оныкларыбызның кайгы-хәсрәтен күрмичә, Раббыбызның җәннәтләрендә очрашырга насыйп булса иде.

**Җәлил хәзрәт Фазлыев,**
Балтач районы имам-мөхтәсибе,
ТР баш казые



Фото: авторның шәхси архивыннан

# ХАҖ, ГОМРӘ КЫЛУНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ

## КОРЪӘНИ КӘРИМ АЯТЬЛӘРЕНДӘ ҺӘМ ХӘДИСЛӘРДӘ ИСКӘ АЛЫНГАН НӘСЫЙХӘТЛӘР

**Хөрмәтле дин кардәшләребез, мөбарәк хаҗ ае дәвам итә, хаҗиларыбыз хаҗның төп гамәлләрен башкарды, дип әйтү дә ялгыш булмас. ИншәАллаһ, Аллаһының рәхмәте белән, тиздән изге җирләрдән кайтучыларыбызны да каршы алырбыз. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә кардәшләребезнең кылган хаҗларын кабул кылса иде, дигән теләктә калыйк. Хаҗ гамәленең фазыйләте, олуглыгы, аның хакында күркәм динебездә нәрсәләр әйтелүен кабат искә төшерсәк иде. Бу нәсыйхәтләр киләсе елларга хаҗ сәфәренә барырга ниятләүче мөэмин-мөселманнар өчен дә бер файдалы мәгълүмат, рухландыру чыганагы булсын.**

***1. Хаҗ кылуны ашыктыру***

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хаҗ кылырга ашыгыгыз, чөнки берегез дә үзенә әҗәл кайчан ирешәсен белми», – дигән (Әбү Давыд).

Башка бер хәдистә: «Хаҗны яшь чагында кылыгыз», – диелгән.

***2. Хаҗилар – Аллаһы Тәгаләнең кунаклары***

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән китерелә: «Зур һәм кече хаҗ кылучылар Аллаһыга килгән вәкилләр булып торалар. Әгәр дә алар Аллаһыга ялварсалар, Ул аларга җавап бирер, Аннан ярлыкауны сорасалар, Ул аларны гафу итәр» (Ән-Нәсаи, Ибне Мәҗе).

***3. Изге сәфәр белән бәйле чыгымнардан курыкмаска кирәк***

Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә тапшырган хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның гомрәсе турында: «Дөреслектә, син үзеңнең аруың һәм чыгымнарың бәрабәрендә әҗер алырсың», – дигән (Әл-Хәким).

***4. Хаҗга баручы хатын-кызның мәхрамы***

Хәдистә әйтелгән: «Аллаһыга һәм Кыямәт көненә ышанган хатын-кызга якын туганыннан башка бер көнлек сәфәргә чыгу рөхсәт ителми (Әл-Бохари, Мөслим).

***5. Тәлбия әйтүнең әһәмияте***

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем генә тәлбия әйтсә дә, аның уң ягында да, сул ягында да булган бар нәрсә – ташлар, агачлар һәм җир йөзендә күз карашы белән иңләп булган бөтен нәрсә аның белән бергә тәлбия әйтә» (Әт-Тирмизи, Ибне Мәҗе).

***6. Гомрәне кат-кат кылып булуы***

Ибне Габбас Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үз гомерендә 4 мәртәбә гомрә кылганлыгы турында әйтә: Хөдәйбия вакыйгасы вакытындагы гомрә, киләсе елда зөлкагъдә аенда кылынган гомрә, өченчесе – Җигъраннан кылынган гомрә һәм дүртенчесе – хаҗ белән кылынган гомрә (Әхмәд, Әбү Давыд, Ибне Мәҗе).

***7. Хаҗ һәм гомрә кылуның әҗере (гөнаһлардан, мохтаҗлыктан арындыруы, җәннәтле итүе)***

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гомрә бер гомрә белән икенче гомрә арасында кылынган гөнаһларны юкка чыгара, ә дөрес итеп кылынган хаҗның әҗере бары тик җәннәт», – дигән (Әл-Бохари, Мөслим).

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһедән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дигәне риваять ителгән: «Хаҗ һәм гомрә кылуны чиратлаштырыгыз, чөнки, дөреслектә, тимер күрүге тимерне, көмешне һәм алтынны чистарткан кебек, алар да сездән гөнаһларны һәм хәерчелекне куарлар, ә дөрес итеп кылынган хаҗның әҗере бары тик җәннәт кенә булыр», – дигән (Имам Әхмәд).

Хәдистә әйтелгән: «Кем Аллаһы ризалыгы өчен дип хаҗ кылса, аннары начар сүзләрдән һәм хәлләрдән үзен тыйса, яңа туган бала сыман гөнаһлардан чистарган хәлдә кайтыр» (Имам Әл-Бохари).

***8. Рамазан аенда кылган гомрәнең савабы***

Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аенда кылган гомрә өчен хаҗ кылган хәтле савап булыр», – диде (Имамнар Әхмәд, Ибне Мәҗе).

Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһедән тапшырыла: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм саубуллашу хаҗыннан кайткач, әнсарлардан булган Өмме Синән исемле хатыннан: «Безнең белән хаҗ кылырга сиңа нәрсә комачаулады?» – дип сораган. Аңа җавап итеп ул: «Минем иремнең бары тик ике генә сугару дөясе бар иде, ул бер сугару дөясен безгә калдырып, шуларның икенчесендә хаҗга китте», – дигән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан ае җиткәч, гомрә кыл, чынлыкта, Рамазанда кылган гомрә минем белән бергә кылган хаҗга тиң», – дигән.

***9. Кәгъбәтуллаһта тәваф кылучылар өчен савап***

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен җиткергән: «Тәваф кылучыга аның һәрбер аяк күтәрүе һәм төшерүе өчен савап язылыр, гөнаһы сөртелер һәм дәрәҗәсе күтәрелер» (Имамнар Әхмәд, Әт-Тирмизи, Әл-Хәким).

***10. Ике Харам мәчетләрендә (Мәккә һәм Мәдинәдә) укылган намазларның дәрәҗәсе***

Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһедән китерелгән хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Минем шушы мәчетемдә (Мәдинәдәге Пәйгамбәребез мәчете) укылган намаз башка мәчетләрдә укылган намазларга караганда мең мәртәбә яхшырак, бары тик «Әл-Харам» (Мәккәдәге «Әл-Харам») мәчетеннән тыш, чөнки «Әл-Харам» мәчетендә укылган намаз башка мәчетләрдә укылган намазлардан йөз мең мәртәбә яхшырак» (Әхмәд, Ибне Мәҗе).

***11. Хаҗда «Раббәнә» догасын уку***

Хаҗга килгән кавемнәрдән кайберләре: «Ий, Аллаһы, бу елны яңгырлы кыл, яхшы балалар туа торган ел кыл», – дип дога кылганнар. Аллаһыдан дөньялык өчен генә сорап, Ахирәт өчен сорарга онытканнар.

Аллаһы Тәгалә андый кешеләрнең догалары дөрес түгеллеген бәян итеп,

ике дөньяның рәхәтенә чакыра торган доганы «Раббәнә»не («Әл-Бәкара» сүрәсе, 201 нче аять) иңдерә.

Габдулла бине Габбастан риваять кылынган хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бәйтуллаһның почмагыннан үткәндә, «Әәмин» дип торган фәрештәне күрдем. Аның яныннан үтсәгез, «Раббәнә»не укыгыз», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кәгъбәтуллаһта тәваф кылганда, Йәмән почмагыннан Кара таш почмагына кадәр «Раббәнә» догасын («Әл-Бәкара» сүрәсе, 201 нче аять) укып барган (Әбү Давыд, Әл-Хәким).

***12. «Кара таш»ның әһәмияте***

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән китерелә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм «Кара таш» турында түбәндәгеләрне әйткән: «Аллаһы белән ант итәм, ул Кыямәт көнендә кайтарылыр һәм аның күрә торган күзләре булыр, сөйли торган теле булыр һәм ул аңа дөрес рәвештә (Аллаһыга буйсынып һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ияреп) кагылган кешеләр файдасына шәһадәт китерер» (Сахих әт-тәгъриб, 2/28).

***13. Кәгъбәтуллаһта тәваф үткәч ике рәкәгать намаз уку***

Тәваф кылганнан соң «Ибраһим Мәкаме» артында, андый мөмкинлек булмаса, Әл-Харам мәчетенең башка җирендә ике рәкәгать намаз укыла. Беренче рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң «Әл-Кәфирун», ә икенчесендә – «Әл-Ихлас» сүрәсен укырга киңәш ителә. Бу сүрәләрне белмәгән очракта башка сүрәләрне дә укырга ярый» (Имам Мөслим).

***14. Сәгый кылуның вәҗиблеге***

Җаһилият вакытында Сафа тавында потлар куелган булган. Кешеләр сәгый кылганда алар янына килеп җиткәч, потларны олылыйлар иде. Ислам дине килеп, ширекне тыйгач, мөселманнар Сафа һәм Мәрва арасында сәгый кылу ширек эш дип уйлап, аны кылмадылар.

Аллаһы Тәгалә бу эштә гөнаһ юклыгын аңлатып, «Әл-Бәкара» сүрәсенең 158 нче аятен иңдерде: **«Һичшиксез,** [Мәккәдәге] **Сафа һәм Мәрвә** [калкулыклары] **– Аллаһының** [Ислам] **билгеләреннән. Бәйткә хаҗ яки гомрә кылган кешегә** [Сафа һәм Мәрвә арасында чабып] **ул икәвен тәваф кылудан бернинди гөнаһ юк».**

***15. Зәм-зәм суының куәте***

Кыйсса: Хаҗәр анабыз Сафа тавы белән Мәрва арасында су эзләп 7 тапкыр әйләнгән. Мәрва тавында тавыш ишетеп, туктап калган. Улы яткан урынга килгәч, Җәбраил фәрештә җиргә канаты белән кагылып ясаган чокырдан су бәреп чыкканын күргән. Һаҗәр йөгереп барып су юлын тоткан һәм туфрак белән уратып: «Зәм-зәм», – дигән. Бу «тукта-тукта»дигән сүз булган.

Хәдистә әйтелгән: «Аллаһы Һаҗәргә рәхимле булсын, әгәр дә ул ашыкмаган булса, Зәм-Зәм иң куәтле чишмә булыр иде», – ягъни, әгәр дә ул чишмәне туфрак белән уратып алмаган булса, чишмә бертуктаусыз агар иде, хәтта тирә-якны су басар иде (Имам Әл-Бохари).

***16. Зәм-зәм суының шифасы***

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Зәм-зәм суын эчкән вакытта: «Әй, Аллаһым, Синнән файдалы гыйлем, киң ризык һәм барлык чирләрдән шифа сорыйм», – дип әйтә торган булган (Әл-Хәким).

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Зәм-зәм суын ни өчен эчкән булсаң, шуңа файда бирер», – дигән (Ибне Габбас, Әхмәд, Ибне Мәҗе).

***17. Хаҗны җиренә җиткереп үтәү һәм хатын-кызларның тырышлык куюы***

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән китерелә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Нинди гамәл иң яхшысы?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләгә, аның Пәйгамбәренә ышану», – дип әйткән. Сәхабәләр: «Тагын нинди гамәл?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аннан соң иң  яхшы гамәл Аллаһы Тәгалә юлында тырышлык кую», – дигән. Сәхабәләр: «Аннан соң иң яхшы гамәл нәрсә?» – дип кабат сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиренә җиткерелеп үтәлгән хаҗ», – дип җавап биргән.

Гайшә радыяллаһу ганһәдән китерелә, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Аллаһы Тәгалә юлында көрәшү иң хәерле  гамәл. Бәлки безгә – хатын-кызларга да бу көрәштә катнашырга кирәктер?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатын-кызлар өчен иң күркәм көрәш – җиренә җиткереп үтәлгән хаҗ», – дип әйткән.

***18. Хаҗ тәмам булгач Аллаһы Тәгаләне зикер итү***

Имам Нәсаи риваять кылуынча, җаһилият вакытында кешеләр хаҗ гамәлләрен үтәгәч, Мина белән тау арасында торып, ата-бабаларының фазыйләтләрен саный иделәр. Аталарының эшләреннән башка нәрсәләрне зикер кылмыйлар иде.

Бу гамәлнең дөрес түгеллеген аңлатып, Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкара» сүрәсенең 200 нче аятен иңдерде: **«Хаҗ гыйбадәтләрегезне кылып бетергәннән соң,** [җаһилият дәверендә хаҗ беткәч, Минада туктап] **аталарыгызны искә алган кебек яки тагын да ныграк Аллаһыны зикер кылыгыз».**

***19. Хаҗда барлык хаҗиларның да бертигез булуы***

Җаһилият чорында Кораеш кабиләсе башка гарәпләрдән үзләрен өстен санаган. Хаҗ кылганда Гарәфәттә башкалардан аерым торганнар, Гарәфәттән төшкәндә дә аерым төшкәннәр.

Аллаһы Тәгалә кораешләрнең бу урынсыз эшләрен дөресләп, Коръәндә болай дип әйтә: **«...кешеләр** [күпләп] **агылган җирдән** [Гарәфәттән] **сез дә төшегез һәм** [кылган хата-кимчелекләрегез өчен] **Аллаһыдан мәгъфирәт сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле»** («Әл-Бәкара» сүрәсе, 199 нчы аять).

Ислам – тигезлек дине. Бу тигезлек хаҗда аеруча күренә.

***20. Хаҗга бару юлында вафат булган кеше җәннәтле булыр***

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу йорт – Исламның терәге, берәү зур яки кече хаҗ кылучы буларак үз йортыннан әлеге йортка таба юнәлә икән, шул кешегә Аллаһы түбәндәгене вәгъдә итә: әгәр вафат булса – җәннәткә эләгер, исән-имин кайтса – табыш һәм саваплар белән кайтыр».

**Гүзәлия Сәйфуллина,**
«Мөхәммәдия» шәкерте,
Кукмара районы, Түбән Үрәс авылы



Фотоның авторы: torianime / elements.envato.com

**Безләрне юктан бар кылып, Үзенең чиксез нигъмәтләрендә яшәтүче Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә чиксез мактау, шөкерләребез булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават, сәламнәребез ирешсә иде. Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.**

Кеше үзенең яшәеш дәверендә матди керемгә, малга, байлыкка мохтаҗ, чөнки Адәм баласына тормышын камил итеп алып барыр өчен, ризык, кием, торак һәм күп кенә тормыш хаҗәтләре, матди чыгымнар таләп ителә. Ислам дине матди байлыкка, акчага карата нинди мөнәсәбәттә соң? Шушы мәсьәләдә без – мөселманнар нәрсәләрне исәптә тотарга тиеш? Әлеге вәгазебез шуның хакта булыр.

Аллаһы Үзенең гыйлеме һәм хикмәте белән бәндәләре арасында байлык һәм дәрәҗәне бүлеп биргән. Әйе, мөселман кардәшләрем, байлык – ул Аллаһыдан, моның хакта күп кенә Коръән аятьләрендә әйтелә:

***«Һичшиксез, синең Раббың теләгән кешегә** [кайчак] **ризыкны мул итәр һәм тарайтыр. Һичшиксез, Ул – колларыннан хәбәрдар һәм күрүче».***

*«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:30*

Аллаһы Тәгалә кешеләргә малларының, байлыкларының күләмен билгеләгән һәм шул байлыкка ирешү юлларын да күрсәткән. Әмма шуны да онытмыйк: бу дөньяда сәбәп кылу кирәк, Ислам дине безне кәсеп итәргә чакыра. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөньяда мәңге яшим дип кәсеп ит, дөнья эшләреңне алып бар, иртәгәсен үләм дип Ахирәтеңне кайгырт, гамәл-гыйбадәтеңне кыл», – дигән.

Шул ук вакытта тапкан малга сакчыл карарга, аны исраф итүдән сакланырга да кирәк, чөнки байлыкны Аллаһы Тәгалә биргән икән, бу – әманәт, аның өчен Кыямәт көнендә җавап та тотасы булачак. Бер хәдистә: «Кыямәт көнендә дүрт нәрсә турында җавап тотканчы, бәндәнең бер аягы икенчесеннән узмас», – дип әйтелә. Шуларның берсе: байлыгыңны нинди юллар белән таптың һәм шул байлыгыңны нинди юлларга сарыф иттең, дип соралачак икән. Коръәни Кәримдә:

***«Ашагыз, эчегез, әмма** [хәләлне харам итеп, яки харамга катышып, яки туклык чиген узып] **исраф итмәгез. Һичшиксез, Ул** [Раббыгыз] **исрафчы кешеләрне сөйми», – дип әйтелгән.***

*«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:31*

Аллаһының Расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә: «Ашагыз, эчегез, садака бирегез, киенегез, ләкин исрафтан һәм тәкәбберлектән сакланыгыз», – дигән (Имамнар Әл-Бохари, Әхмәд, Әбү Давыд).

Әйе, мөселман кардәшләрем, бу аять һәм хәдисләр безне акчаны, байлыгыбызны кулланганда чамадан чыкмыйча, сакчыллык күрсәтеп кулланырга чакыра. Безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең «Исраф кылмаучы фәкыйрьләнмәс», – дигән мәгънәдәге сүзләре нинди яхшы киңәш! Шул ук вакытта исрафтан сакланыйм, малымны сакчыл тотыйм әле дип, саранлыкка кереп китүдән дә сакланырга кирәк, чөнки мал, байлык мәсьәләсендә гаиләбезнең дә, күршеләребезнең дә, мескен-фәкыйрьләрнең дә хаклары бар. Ислам дине дөнья куып малга, байлыкка ирешүне төп максат итеп куймый, әмма шушы мал белән Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алу, шул байлык белән изгелекләр эшләүне максат итеп куя. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

***«**[Чамасыз саранлык аркасында]* ***Колыңны муеныңа бәйләгән** [кебек каты]* ***итмә,** [кулыңа кергән бернәрсәне таратып]* ***аны бар киңлегенә дә җәймә, юкса соңыннан** [Аллаһы хозурында – исрафта, кешеләр алдында дуамаллыкта гаепләнеп]* ***кимсетелгән һәм үкенечле бер хәлдә калырсың».***

*«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:29*

Бу аять безне садака биргәндә уртача булырга чакыра, саранлык күрсәтеп садака бирмәү яки әз бирү дә, шулай ук барлык малыңны садака итеп таратып, үзеңне авыр хәлдә калдыру да ярамый. Һәркем садакасын үзенең матди хәленә карап бирергә тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Садака ул иманга дәлил», – дип әйткән. Шулай ук садака малга бәрәкәт китерә, икенче бер хәдистә: «Садака биреп, мал кимемәс», – дип әйтелә.

Ислам диненең биш нигезен искә төшерсәк, шуның икесе: зәкят түләү һәм хаҗ кылу өчен матди байлык булу таләп ителә. Ягъни әгәр кешенең акчасы, байлыгы булмаса, ул шушы фарызларны үти алмаячак.

Гаиләләрен матди яктан тәэмин итүче буларак, Аллаһы Тәгалә ирләрне хатыннарыннан өстен кылды. Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

***«Аллаһының** [тирән акыл, оста җитәкчелек, көч, ныклык кебек сыйфатлар белән]* ***берәүләрне икенчеләрдән өстен кылганы өчен һәм малларыннан сарыф иткәннәре сәбәпле, ирләр** [гаилә эчендә әмер бирү һәм тыюлар мәсьәләсендә]* ***хатыннардан өстен торалар», – дип әйтә.***

*«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:34*

Гаиләсен матди яктан тәэмин итүне Аллаһы Тәгалә ирләр өстенә йөкләгән. Гаилә кору да, балалар тәрбияләү дә күп чыгымнар таләп итә. Хәдисләрдә: «Гаиләгә тотылган мал – сарыф ителгән иң хәерле мал була», – дип әйтелә.

Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек насыйп итсен, тормышларыбызга муллык, куаныч, кәсепләребезгә бәрәкәт бирсен, безне түбән хәлгә төшерә торган фәкыйрьлектән һәм тәкәбберлеккә илтә торган байлыктан сакласын.

**Илһам хәзрәт Мохтаров,**
Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме,
Кукмара районы Аш-Буҗи авылы,
имам ярдәмчесе

# Жак Ив Кусто: «Бүгенге фән 1400 елга артта калган»



Фотоның авторы: FabrikaPhoto / elements.envato.com

**Бөек француз галиме Морис Бюкай: «Әгәр мин Коръәнне алданрак өйрәнгән булсам, фәнни ачышларыма сукыр килеш бармас идем, минем кулымда юл күрсәтүче йомгак җебе булыр иде», – дигән.**

Галимнең «Коръән һәм бүгенге фән» дигән китабындагы бер мәкаләсенә күз салыйк әле. «Коръән белән игътибар белән таныша башлаган һәрбер кешене, иң беренче чиратта, андагы темаларның киңлеге таң калдыра. Галәм барлыкка килү, астрономия, үсемлекләр һәм башка тереклек дөньясы, кеше яратылу һәм аның тормышы...

Ә иң мөһиме – бүгенге фәннең төп нигезләре белән таныш кеше аларның Коръән аятьләре белән тулысынча тәңгәл килүен күрми кала алмый. Җирнең һәм тереклекнең килеп чыгуы турындагы бүгенге теорияләргә дә, кеше яратылуга карата фәнни фикерләргә дә, физика-математика өлкәсендәге иң катлаулы проблемаларга да кагыла ул. Коръән безнең эраның VII гасырында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Җәбраил фәрештә аша иңдерелгән.

Галәмнең һәм тереклекнең барлыкка китерелүе Коръәндә болай дип аңлатыла:

***«Күкләр һәм җир** [бер-берсеннән аерылмаган дәрәҗәдә] **ябышкан нәрсәләр иде, шуннан соң Без аларны** [җир һәм күк дип, ике аерым барлык хәленә китердек, бигрәк тә җиде кат күк һәм җирдәге катламнарга] **аердык».***

*«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:30*

Һәм бу факт фәнгә берничек тә каршы килә алмый. Тереклек, дөрестән дә, суда барлыкка килгән. Тере күзәнәкнең төп компоненты – су. Сусыз тормышның булуы мөмкин түгел.

Үсемлекләр дөньясына килгәндә, Коръәндә болай дип әйтелгән:

***«Син туфракны үле һәм коры хәлдә күрәсең. Без аның өстенә су иңдергәч, ул** [уңыш бирү өчен] **хәрәкәтләнә, кабара һәм** [караучыларны сөендерә торган] **күркәм парлар** [һәм төрле-төрле үсемлекләр] **үстерә».***

*«Әл-Хаҗ», 22:5*

Әлеге аять хәзерге фән нәтиҗәләре белән тулысынча тәңгәл.

Коръәндә бал кортлары, үрмәкүчләр һәм кошлар телгә алына. Алар белән галимнәрнең дә кызыксынулары бик зур. Коръәндә:

*«[Расүлем!] **Синең Раббың бал кортына вәхи итте: «Тауларда, агачларда һәм** [кешеләр төзегән] **корылмаларда оялар кор. Шуннан соң, һәртөрле җимешләрдән туклан һәм Раббың җиңеләйткән юлларда йөр». Аларның карыннарыннан** [ел фасылларының, чәчәкләрнең, бал кортларының яше үзгәрүгә бәйле] **төрле төсле һәм кешеләр өчен шифа булган бер эчемлек чыга. Һичшиксез, боларда фикер йөртүчеләр өчен билге бар»,** – диелгән.*

*«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:68-69*

Бүгенге фән бал кортларының таң калдырырлык оешканлыгын, бал бирә торган чәчәкләргә кадәр күпме ара очарга кирәклегенә кадәр мәгълүмат бирә алуын ачыклады.

Кошлар хакында Коръән аяте мондый сүзләр әйтә:

***«Алар** [инкяр итүчеләр] **күктә** [очарга дигән] **әмергә буйсынган кошларны күрмиләрме әллә? Аларны бит Аллаһы гына тота».***

*«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:79*

Бүгенге фән раславы буенча, кошларның нәкъ шул вакытта, нәкъ шуның кадәр ераклыкка очарга тиешлекләре аларның генетик кодларына программа булып салынган.

Инде сөт турында искә алыйк. Изге Китабыбызда:

***«Һичшиксез, терлектә сезнең өчен бик зур гыйбрәт бар. Без сезгә аларның эчендә тизәк белән кан арасында булган һәм эчүчеләр өчен тамактан җиңел үтә торган саф сөт эчерәбез»,** – дип әйтелә.*

*«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:66*

Сөт үзенең барча компонентлары белән сөт бизләрендә ясала, ә ул кушылмаларны безләргә кан алып килә. Барча файдалы матдәләр канга ашаган ризыктан күчә һәм бу эчәк кырыеннан үтә торган кан юллары тарафыннан башкарыла. Әлеге фәнни концепциянең дөнья күрүенә әле күп еллар үтмәде. Коръәндә телгә алынган кан әйләнеше системасы хакында мәгълүматны Харвей исемле галим Коръән иңгәннән соң 10 гасыр (1000 ел!) үткәч кенә ачыклаган.

Бөек француз галиме Морис Бюкай: «Коръәнне һәм кеше акылының бүгенге казанышларын чагыштырып өйрәнү аларның бер-берсенә тәңгәл икәнлеген күрсәтә. Ул заманның белем дәрәҗәсе нинди булганын исәпкә алсак, телибезме-теләмибезме бер генә нәтиҗәгә киләбез: кешенең ул вакытта мондый ачышлар ясарга мөмкинлеге булмаган. Шуңа күрә Коръән аятьләренә зур хөрмәт белән карарга, бу могҗизага аңлатманы материалистик фикер йөртү белән генә бирә алмавыбызны танырга тиеш булабыз», – ди. Тагын берничә галимнең фикерен тыңлыйк әле. Болары «Коръән – фәнни белем чишмәсе» дигән китаптан алынды.

Профессор Альфред Корнер, АКШның танылган галиме, биолог: «Мөхәммәд пәйгамбәр 1400 ел элек әйткән сүзләрнең дөреслеге хәзерге фәннең яңа ысуллары ярдәмендә расланды. Атом-төш физикасы турында берни белмәгән ул заман кешесе үз акылы белән генә хакыйкатькә барып җитә алмый. Ә хакыйкать мондый – Җир һәм башка планеталар бер үк төрле яратылган. Коръәндә бирелгән мәгълүмат дөрес, хак һәм ул хәзерге заманның фәнни ысуллары белән раслана бара». Нәкъ шушы ук фикерне профессор Тасажа Тасажон да (Таиландның анатомия өлкәсендәге зур галиме), профессор Рау да (АКШның диңгез геологиясен өйрәнүче галиме) куәтли.

*(Дәвамы 8 нче биттә)*

## ГАЕТ АЛДЫННАН ЧҮПРӘЛЕ МӨХТӘСИБӘТЕНДӘ ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛҮДӘН СОҢ МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ




**Зөлхиҗҗә аеның 3 нче көнендә (21 нче июньдә), Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында төзекләндерелүдән соң тантаналы рәвештә «Ихлас» мәчете үз ишекләрен ачты.**

Олуг Корбан гаете алдыннан әлеге күркәм вакыйганы хөрмәтләп, чүпрәлеләрнең сөенечен бүлешергә күпләгән кунаклар, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, иганәчеләр килде. Әйтергә кирәк, әлеге авылда ике мәчет эшли: 1990 елда төзелгән Үзәк мәчет һәм 2003 елда салынган «Ихлас» мәчете. Үзәк мәчет 2021 елда төзекләндерелеп ачылган булса, быел исә авыл халкы, аеруча «Цильна» җәмгыяте җитәкчесе Барис Гафуровның тырышлыгы һәм матди ярдәме белән «Ихлас» мәчете дә зур ремонт эшләреннән соң кулланылышка тапшырылды. Биредә башкарылган һәм танып булмаслык үзгәрешләрне күреп, танышып, зур рәхмәт сүзләрен белдерергә килүчеләр арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Чүпрәле муниципаль районы башлыгы Марат Гафаров, районның дин әһелләре, мөгаллимнәр, кайткан кунаклар һәм, әлбәттә, җирле мәхәллә халкы бар иде.

Тантанага җыелган халыкны сәламләп, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин тантанада катнашучыларга нәсыйхәт сүзләрен ирештереп, рухи-әхлакый кыйммәтләрне ныгытуда мәчет һәм мәдрәсәләрнең ролен билгеләде, рухи яктан чистару, пакьләнү өчен мәчетләргә йөрү кирәклеген билгеләп үтте. Ул шулай ук мәчет салуның фазыйләтләрен искә төшереп, хәдис китерде: «Кем дә кем бер мәчет төзесә, Аллаһы Тәгалә шундый ук сыйфатта бу кешегә җәннәттә йорт бүләк итәр». Аннары якынлашып килә торган Корбан гаете уңаеннан, корбан чалу йоласын башкаруның әһәмиятен ассызыклап үтте: «Аллаһы Тәгаләгә чалган корбаннарыгызның итләре дә, каннары да кирәк түгел. Раббыбызга бары тик сезнең тәкъвалыгыгыз ирешә». Аллаһы Тәгалә чалачак корбаннарыбызны, тәгать-гыйбадәтләребезне, садакаларыбызны кабул итсен, гөнаһларыбызны гафу итсен!

Алга таба Камил хәзрәт мәчетне төзекләндерүдә зур өлеш керткән иганәчеләргә рәхмәт хатлары тапшырды. «Цильна» җәмгыяте җитәкчесе Барис Гафуровка, иганәче Илнур Садриевка, мәчетне төзекләндерү эшләрен җитәкләүче инженер-төзүче Илдар Җаббаровка, Кече Чынлы «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы Рифкать Туктаровка, мәчетнең мөәзине Рифкать Җамалетдиновка мөфтинең рәхмәте белдерелде.

Әйтеп үтәргә кирәк, Кече Чынлы авылы «Ихлас» мәчетенә 2003 елда беренче нигез ташы салына һәм шул ук елның ноябрь аенда ачыла. Бер катлы мәчетнең намаз залы 100 квадрат метрны тәшкил итә. Төзекләндерү эшләре быел март айларында башланды һәм өч ай эчендә эшләнеп тә бетте: мәчетнең түбәсе алыштырылды, яңа манара куелды, янкорма салынды (анда ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханә, аш бүлмәсе, котельная урын алды), мәчетнең эче һәм тышы заманча төзелеш материаллары белән тышланды, идәннәр, тәрәзәләр, электрүткәргечләр, су һәм җылылык системалары алыштырылды, тирә-ягы койма белән әйләндереп алынды. Гыйбадәт йортына яңа келәмнәр җәелде, яңа өстәл һәм утыргычлар, аш-су өчен кирәк-яраклар сатып алынды. Мәчет үз эченә берьюлы 130 кешене сыйдыра ала. Мәчетнең имамы – Рифкать хәзрәт Туктаров.

Хәзерге вакытта Чүпрәле мөхтәсибәтендә 26 мәчет эшли, соңгы елларда 5 мәчет төзекләндерелде.

**dumrt.ru** сайтыннан алынды

## ЖАК ИВ КУСТО: «БҮГЕНГЕ ФӘН 1400 ЕЛГА АРТТА КАЛГАН»

*(Дәвамы. Башы 7 нче биттә)*

Профессор Шрейдер (Грециянең галиме, океанолог) мондый тәкъдим ясый: «Дөньяның барышы Коръәндә әйтелгәннәрне раслый. Галимнәрнең бүгенге ачышлары – 1400 ел элек Коръәндә әйтелгән Хакыйкать. Минем уйлавымча, бу турыда дөньяның барлык галимнәре дә аңлавы бик мөһим».

Бөек француз галиме, океанолог Жак Ив Кусто: «Мин ант итәм, бүгенге фән Коръән аятьләреннән 1400 елга артка калган», – дип әйтеп калдырган. Торонто университетының анатомия һәм эмбриология галиме профессор Кайт Морның да гаҗәпләнүенә чик юк: «Мөхәммәд ничек итеп эмбрион һәм аның үсеш фазаларын 1400 ел элек шуның кадәр төгәл аңлатып бирә алган? Безнең галимнәр бу турыда әле соңгы елларда гына белә алдылар. Мин Коръән аятьләренең кеше яратылуга кагылышлы булганнарын аңлатуга өлеш кертә алуым белән бик бәхетле», – ди галим.

«Минем уйлавымча, белемебез арткан саен, фәнни-техник казанышлар үскән саен, без Коръән аятьләрен һәм хәдисләрне тирәнрәк өйрәнеп, алардагы фәнни мәгълүматны аңлый һәм аңлата алачакбыз. Фән белән дин арасындагы киртәләр, Коръән аятьләрендәге һәм хәдисләрдәге хакыйкать ярдәмендә җимерелер, дип бик ышанасы килә», – дип йомгак ясый профессор Кейс Мор.

**Рәзилә Кукушкина**

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ ДӨНЬЯГА КИЛҮЕ



Фотоның авторы: yusufdemirci / elements.envato.com

Рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көне иде. Олы яшьтәге Габделмотталиб оныгының туу хәбәрен көтеп, йөзен Кәгъбәтуллаһ тарафына борды. Йәмән җирләренең хакиме Әбраһаның үз гаскәре һәм зур филләре белән, Кәгъбәтуллаһны җимерергә дип, изге җирләргә юнәлгән вакытын искә төшерде. Шулчак Мәккә җирләренә җитәрәк ул кырларда йөргән барлык хайваннарны үзенә алды һәм Габделмотталибка, сугыш игълан итүен әйтеп, үз кешесен җибәрде. Ул Мәккә шәһәренең башлыгы Габделмотталиб, шәһәргә һөҗүм ясамавын үтенеп, ялвара башлар дип көткән иде. Әмма ни гаҗәп, Габделмотталиб Әбраһадан дөяләрен кайтаруын гына сорады һәм гаҗәпкә калган Әбраһага: «Бу дөяләрнең хуҗасы – мин һәм аларны мин якларга тиеш, Кәгъбәтуллаһ Аллаһының яклавында, димәк, аны Ул кайгыртачак», – дип җавап бирде. Әбраһаның ачуы көчле иде, ул дөяләрне Габделмотталибка кайтарып бирүләрен кушты һәм гаскәренә һөҗүм итү әмерен бирде.

Моннан соң гаҗәеп хәлләр башлана: Кәгъбәтуллаһны җимерергә дип җибәрелгән филләр җиргә ятып, алга таба барудан баш тарта. Шулчак күктә томшыкларына һәм тәпиләренә кечкенә ташлар эләктергән кошлар көтүе хасил була. Бу ташларга өстенә төшәргә тиеш булган кешеләрнең, ягъни Әбраһа гаскәре әһелләренең исеменә кадәр язылган була. Кошлар ташны билгеле кешеләргә атканнан соң, бу кешеләр шунда ук һәлак була. Күпмедер вакыттан соң Әбраһаның гаскәреннән берәү дә калмый. Шулай итеп, Раббыбыз Аллаһы Кәгъбәтуллаһны һөҗүмнән саклап кала һәм бу вакыйга хөрмәтенә әлеге елны «Фил елы» дип йөртә башлыйлар.

Бу вакыйга Коръәни Кәримдә болай дип тасвирланган:

***«[Расүлем!] Раббыңның фил ияләренә ни кылганын күрмәдеңме? Ул аларның [Кәгъбәне җимерү] хәйләсен бушка чыгармадымы? Аларның өсләренә көтү-көтү кошлар җибәрмәдеме? Алар [кошлар] аларга яндырылган балчыктан ташлар аталар иде. Ул [Аллаһы Тәгалә] аларны [бөҗәкләр тарафыннан] ашалып беткән иген яфраклары кебек итте».***

*«Әл-Фил», 105*

### «КЕШЕЛӘР АНЫ МАКТАСЫН ӨЧЕН»

Бу вакыйгаларны искә төшереп торган Габделмотталиб: «Шатлыклы хәбәр бар, Габделмотталиб, синең оныгың туды» дигән көчле тавышка сискәнеп китә. Аңа оныгы туу хакында шатлыклы хәбәр китергән булалар. Ул тиз-тиз өенә ашыга. Өенә кергәндә бала елаган тавыш ишетә. Аны шатлык һәм сагыш хисләре биләп ала, ул күптән түгел үлгән улы – шушы сабыйның әтисе Габдулланы искә ала. Габделмотталиб Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әнисе хәзрәти Әминәдән:

– Балага нинди исем бирәбез? – дип сорый.

Хәзрәти Әминә:

– Мөхәммәд, – дип җавап бирә.

Габделмотталиб нәселендә мондый исемле кеше булмаганга күрә, ул уйга кала һәм шуннан соң аңа хәзрәти Әминә төш күрүе һәм төшендә баласына Мөхәммәд дип кушарга әйтелүе хакында сөйли. Габделмотталиб хәзрәти Әминә белән килешә һәм Раббыбызга шөкер сүзләрен җиткерер өчен, Кәгъбәтуллаһка китә. Оныгына нигә шушы исемне бирүе хакында соралгач, ул: «Кешеләр аны мактасын өчен», – дип җавап кайтара.

Сәхифәне **Айсылу Юлдашева** әзерләде

## ТР МДНнең «Хозур» нәшрият йорты «Дини календарь. 2024» басмасын нәшер итте

«Дини календарь. 2024» басмасы милади һәм һиҗри буенча көннәр исәбе, күп кенә регионнар өчен намаз вакытлары белән таныштыра. Әлеге басма дини бәйрәмнәрнең тарихы, мөһимлеге, пәйгамбәрләр тарихыннан гыйбрәтле вакыйгалар, үгет-нәсыйхәтләр, әдәп-әхлак, фикһ, гакыйдә мәсьәләләре белән тулыландырылган.




**Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.**
**Кибет:** Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6нчы йорт.
Тел.: +7 960 072-74-63;
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09;
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru

РЕКЛАМА 12+

# БАЛТАЧ РАЙОНЫНДА ӘХЛАК ФӘНЕ УКЫТЫЛУГА 25 ЕЛ


Фото: авторның шәхси архивыннан

**Балтач районы мәктәпләре ул яктан бәхетле дими, ни дисең. Менә чирек гасыр инде балаларга мәктәпләрдә әхлак дәресләре укытылып килү – шуның матур бер асыл дәлиле.**

Әхлакый юнәлешне өлге итеп алып, һич кенә дә ялгышмадылар райондашларым. Мәгариф кысаларында башкарылган бу гамәл, чыннан да, хуплауга һәм олылауга лаек. Заманында дәресләр расписаниесенә кертелеп укытылса, бүген ул түгәрәк формасында, дәресләрдән соң, башлангыч сыйныфларда гына тормышка ашырыла. Баштарак ул 5 класстан – 9 класска кадәр укытыла иде. Мин әле аның Алан урта мәктәбендә, беренчеләрдән булып, ничек җиренә җиткереп укытылуын да, аңа ничек хөрмәт һәм игътибар булуын да ачык хәтерлим. Ул чактагы мәктәп директоры Гүзәл апа Бариева әхлак укытуның кирәклеген, мөһимлеген аңлап, әхлак дәресләрен инглиз теле урынына, гарәп теле итеп кертеп булуын да матур өлге итеп раслады. Теләк булгач, ул эшнең юлларын ничек табып булуын да ачык һәм анык итеп күрсәтте. Балаларның да, әтиәниләрнең дә бу яңалыкны хуплап, яратып кабул итүләрен дә беләм. Менә бит, уйлагач юлы да, мөмкинлекләре дә табыла. Алан мәктәбенә мәдрәсә тәмамлап, гарәп теле укытучысы булып эшкә кайткан Илшат Корбанов та сынатмады: әхлакый һәм дини тәрбияне һәр баланың күңеленә, җанына җиткереп салырга тырышты ул. Дөрес, беренче елларда бу фәнне Сибагатуллина Гөлназ балаларга үтемле итеп, яратып төшендерде. Ул иске татар телен, гарәп телендәге язмаларны укытуга өстенлек бирде. Берәр елдан, әхлак укытуны 2 класстан алып 11 класска кадәр итеп кертүне кирәк дип таптылар аланлылар. Ел саен диярлек әхлактан республика күләмендә семинарлар да булып торды. Аларда мөфтияттән дә кунаклар бик теләп катнашты. Әхлак укытуның эчтәлеге белән танышу өчен, җөмһүриятебезнең Нурлат, Әлмәт, Балык Бистәсе, Бөгелмә, Мамадыш, Кукмара һәм башка районнарыннан бик күп сандагы делегацияләрнең килгәннәрен мин үзем дә ачык хәтерлим. Аларның барысына да күрсәткән ачык дәресләрне, чараларны санасаң да, очына да, кырыена да чыга торган түгел!.. Алан мәктәбендә Корбан  һәм Ураза гаете бәйрәмнәре, Коръән укучылар бәйгеләре ел саен матур итеп уздырыла иде. Һәр балага да күчтәнәчләр тутырылган пакетлар өләшеп, кызыксынуларын, теләкләрен арттырырга тырышты Гүзәл апа Бариева. Озак көттермәде, Аллаһы Тәгалә әҗерен дә бирде. Мәктәпнең 5 га җирендә үстерелгән бәрәңгене сатып, уку йортына барлык кирәк-яраклар сатып алынды. Балалар сабантуйлары үткәрелде, бүләкләр өләшенде. Мәктәп, чыннан да, әхлак, тәрбия үзәгенә әверелде. Авыл халкы белән дустанә мөнәсәбәт урнаштырылды.

Элеккеге чорлар белән чагыштырганда, хәзерге көндә, район мәктәпләрендә әхлак укытуда беразчигенү сизелә сизелүен. Тик аз булса да, әхлак укытучылары, бүген инде түгәрәк җитәкчеләре: «Биргән белән бирмәгән бер түгел», – дип тырыша.

Әхлак дәресләре район мәгариф тарихында истәлекле булып саналган 1998 елларда кертелде дә инде. Аның өчен ул вакытта район мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев тырышып йөреп эз салмаса, сүзен эше белән расламаса, бүген генә аны мәктәпләргә кертеп булыр идеме икән?! Шул ук елны аның программасы да төзелде, дәреслекләр дә алып кайтып таратылды, кыскасы, укыт кына, тиешле тәрбияне бир генә. Бердәм булып, аның кирәклеген тоеп тотынган ул чор мәктәп директорларының да эше мактауга һәм олылауга лаек. Чагыштырып утырам да, ул заманның мәктәп җитәкчеләренә соклану катыш горурлык белән, үзгә бер ярату белән карыйм мин. Ничектер күмәкләшеп, бердәм булып Җәлил хәзрәтнең бу тәкъдимен күтәреп тә алдылар алар. Икеләнергә, артка борылып карарга ирек калдырмыйча тотындылар. Бер генә дә каршы әйткән җитәкче, кирәкме икән ул дип кирегә «сукалаган» укытучы, «юк белән баланың башын катырмагыз» дип ярсыган ата-ана булдымы икән?! Юктыр, һәрхәлдә әхлакый-дини белем бирүгә каршы килүче табылмагандыр. Халык мәкалендәгечә, тимерне кызуында суктылар да инде алар. Шунда ук һәр мәктәпкә укытучысын да табып куйдылар. Район бюджетыннан хезмәт хаклары да билгеләнде. Районыбыз халкы иң беренче шул вакытта эшләгән мәктәп җитәкчеләренә, аннан шул чорның район мәгариф бүлеге җитәкчесе булган Хәмит Хафиз улы Гәрәевка (хәзер инде мәрхүм, урыны җәннәттә булсын), аннан соң район мәгарифе белән озак еллар намуслы җитәкчелек иткән Вакыйф Мансур улы Зәкиевка олуг рәхмәтле. Район мәктәпләрендә 25 ел элек әхлак укытуның орлыкларын салган, бүген исә шытымнарын барлаучы һәм милли тәрбия бирүдә саллы эз калдырып, район мәгариф тарихына алтын хәрефләр белән уелып калучы, соклангыч тәрбия үзәген булдыруда җитлеккән һәм беренчел җимешләрен биргән данлы да, шанлы да булган әлеге еллар алдында, дөрестән дә, баш иясе килә.

Әхлак укытучыларының быелгы еллык семинары да шушы мөһим датаны көздә тотып оештырылган иде. Ел саен әлеге матур чараның

кадерле кунагы булып килгән мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да быел да традициягә тугрылык саклаган иде. Район мәдрәсәсендә белем алган һәм укуны уңышлы тәмамлаган шәкертләргә дипломнар тапшыруда да ул көтелгән кунак булды. Әхлак укытучыларының (түгәрәк җитәкчеләре дип атыйсым килми) һәрберсе дә бу көнне дулкынланып көтте. Еллык семинарда ачык дәресләр, ачык чаралар гына күрсәтелми, ә монда еллык эшкә йомгак та ясала бит әле. Тырышып эшләгәннәргә балалар күңелен яулап, ачык чаралар үткәреп, конкурсларда, бәйге-ярышларда катнашкан һәм укучыларны катнаштырган укытучыларга мөфтинең һәм район мөхтәсибәтенең мактау кәгазьләре дә тапшырыла, бүләкләр дә бирелә.

Районда әхлак укытуның матур бер күрсәткече булган әлеге семинарда күрше Башкортстаннан да кунаклар бар иде. Димәк, быелгысы Бөтенрәсәй статусын алды, дисәк тә ялгышмабыз. Балтачның бу матур эшенең алымы республикабыз районнарын гына түгел, ә бәлки күрше республикаларны да җәлеп иткән, күрәсең! Район хакимияте башлыгы Рамил Рәшит улы Нотфуллинның да семинарда катнашуы нур өстенә нур булды. Шулай ук үткен фикерле, йөзеннән иман нурлары сибелеп торган, үтә дә кешелекле «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мәдрәсәсе» директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин да бу истәлекле чарада катнашуы һәм үтемле сүзе белән үзгә бер матур, күркәм ямь өстәде. Чарада Балтач районы мәдрәсәсе җитәкчесе, мөгаллиме Рамил хәзрәт Бикбаев та, Балтач бистәсе мәчетләре имамнары да бик теләп катнашты. Шулай ук Түбән Камадан, Казаннан һәм республикабызның башка районнарыннан да семинарга килүчеләр – балтачлыларның әхлак укытуның үрнәк тәҗрибәсен өйрәнергә теләүчеләр байтак иде. Аларның һәрберсенә бүген әхлак укытуда артка чигенмичә, оста төгәллек, оешканлык һәм барча актуальлеген аңлатып, мөһимлегенә басым ясап, төшендереп биргән, асылын ачык итеп күрсәткән Җәлил хәзрәт Фазлыевка без аеруча рәхмәтле. Ул янып йөрмәсә, әхлак укытучыларын үз канаты астына алып, яклап, саклап тормаса, туктаусыз тикшерүләргә чыдап, аз гына хезмәт хакына да эшләүчеләр табылыр идеме икән?!


Фото: авторның шәхси архивыннан


Балтач гимназиясендә уздырылган ачык дәрес, дини-әхлакый якны күздә тотып оештырылгангамы, барлык катнашучыларның да күңелләренә хуш килде. «Заманча белем һәм тәрбия бирүдә әхлак укытуның актуаль мәсьәләләре» дигән темага да очраклы тукталмадык. Бүген, дөресен әйткәндә, әхлак укытудан куркып, шүрләп калган мәктәп җитәкчеләре дә, кызганыч ки, барлыкка килде шул. Ни дисәгез дә, заман үзгәрә, заман белән таләпләр дә, мөмкинлекләр дә, директорлар составы да үзгәрә икән. Әле кабат-кабат әхлак укытырга кирәклегенең мөһимлеген аңлаткач та, куркып, икеләнеп калган мәктәп җитәкчеләрен күреп, аптырап каласың. Шатланып, хәер-фатиха биреп, мөмкинлекләр тудырырга да бит… Әхлак белән дин һәрчак янәшә атлый. Әхлак булмаса, дин булмый, дин булмаса, әхлак булмый. Әнә шуның «дин» дигән сүзеннән дә шүрләп калучылар, юк дисәң дә, бар шул әле бүгенге көндә. Әхлак укытуның нәтиҗәсен, бернинди үлчәүләргә дә салып үлчәп булмавы инде барыбызга да мәгълүм. Аны кг белән дә, тонналар белән дә, мактау кәгазьләре, диплом, сертификатлар белән дә үлчәп булмый. Аның нәтиҗәсенә ышанырга, күпмедер вакыт узганын көтәргә генә кирәк. Әнә шуларны тирәнтен уйлап, балаларга әхлакый белем һәм тәрбия бирүне күздә тотып оештырылган әлеге семинарда Балтач гимназиясенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Идрисова Нурсөя Мөхәрләм кызы да «Уеннан уймак…» (Ә. Гаффарның «Ләк-ләк» хикәясе буенча) дип исемләнгән ачык дәресе белән катнашты. Шул ук уку йортының югары категорияле татар теле укытучысы Рәйсә Шамил кызы Әхмәтова «Хәдисләрдә – хикмәт» исеме астында ачык чара уздырып күпләрне шаккаттырды. Ни дисәгез дә, бу чарада Изге Китабыбыз «Коръәни Кәрим»гә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә дә төпле аңлатма бирелде. Тормыштан алынган күп кенә мисаллар белән ныгытылды.

Әлеге семинар кысаларында яңгыраган һәр сүз, һәр җөмлә – ул мәктәпләрдә әхлак укытуны тукталмыйча, тагын да камилрәк юлларын табып, әхлак укытучыларының абруен күтәреп, хезмәт хакларын арттырып, замана белән атлаучы тәрбияле балалар үстерү булды. Җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә бары әхлаклы, нык иманлылар гына каршы тора алуы турында да фикерләр күп яңгырады. Без бу чарада белемле балалар гына түгел, белемле һәм әхлаклы балаларның гына дөньяда үз юлларын, үз урыннарын таба алачаклары турында да күп сөйләштек. Мәктәпләрдә үткәрелгән бихисап чараларның әхлакка, тәрбиягә корылганда гына файдалы һәм нәтиҗәле булачагына беркем шикләнмичә үз сүзен әйтте. ИншәАллаһ, эшләребез дәвамлы, балаларыбыз иманлы, дөньяларыбыз тыныч, киләчәгебез якты булса иде.

**Рәҗәп Бәдретдинов,**
Балтач районы әхлак укытучыларының методик берләшмә җитәкчесе

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ
№ 06 (335) июнь, 2023 | зөлкагъдә–зөлхиҗҗә, 1444

# Кайсы мөэминнәрнең янчыклары тулырак?



Фотоның авторы: drazenphoto / elements.envato.com

**Һәр мөселманга үлем килгәнче аңа әзерләнү вәҗибтер. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:**

***«Әгәр үлемнән яки үтерелүдән качсагыз,*** *[әҗәлегез җиткән булса]* ***бу качу сезгә файда китермәячәк».***

*«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:16*

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үлем – мөэминнең рәхәтедер».

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Кайсы мөэминнәр артыграк?» – дип соралды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Холык йөзеннән иң күркәме», – дип әйтте. Аннары: «Кайсы мөэминнәрнең янчыклары тулырак?» – дип соралды. Ул: «Үлемне күп зикер итүче һәм үлем өчен күркәм рәвештә әзерләнүче», – диде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Зирәк кеше үзен таныган һәм үлемнән соң булган нәрсәгә гамәл кылган кешедер. Гөнаһлы кеше нәфесенә һәм нәфес теләкләренә иярер, Аллаһы Тәгаләдән котылуны, ягъни ярлыкауны теләр».

## ҖӘННӘТКӘ КЕРҮ АВЫРЛЫГЫ

Акыл ияләренең кайберләре болай дип әйткән: «Дөньяга ышану, дөньяны ярату – наданлыктыр. Дөреслектә, җәннәт – ул ләззәт. Ул ләззәткә итагать белән мәшәкатьләнгән кеше генә ирешер. Хакыйкатьтә, җәннәт – ул байлык. Ул байлыкка бу дөньяда авырлыклар күрмәгән кеше ия булмас. Бары тик дөньяның ләззәтләрен ташлаган кеше генә җәннәткә ия булыр».

Заһидлардан булган берәү икмәктән башка ясмык һәм тоз гына ашый иде. Аңа бер ир: «Нигә син үзеңне яхшырак ризык ашаудан мәхрүм итәсең?» – дип әйтте. Ул заһид: «Мин Раббыма итагать итәр өчен ашыйм һәм җәннәткә өметләнәм. Ә син, алар тирескә әйләнсен өчен, яхшы ризык ашыйсың», – дигән.

Ибраһим бине Әдһәм радыяллаһу ганһедән хәбәр ителә. Ул мунчага керергә теләгән, һәм мунча хуҗасы аны керүдән тыеп: «Бирегә бары түләү белән генә керерсең», – дип әйткән. Ибраһим бине Әдһәм елап: «Әй, Аллаһым, миңа түләмичә шайтаннар йортына керергә рөхсәт бирелми. Ничек минем өчен пәйгамбәрләр һәм сиддыйклар йортына акчасыз, хаксыз керү булыр?» – дигән.

## ЯХШЫЛЫККА ӨНДӘҮ, ЯМАНЛЫКТАН ТЫЮНЫҢ МӨҺИМЛЕГЕ

Әбү Һөрайра Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Шундый кешеләр бар, алар яхшылыкка ачкыч һәм явызлыкка богау булыр. Дөреслектә, кайбер кеше явызлыкка ачкыч һәм изгелеккә богау булыр. Кулында изгелек ачкычлары булучыга ни сөенечтер! Кулында Аллаһы Тәгалә явызлык ачкычларын кылучыга ни үкенечтер! Ягъни шәригать белән әмер итүче һәм тыелган нәрсәләрдән тыючы кеше изгелекнең ачкычы, явызлыкны баглаучыдыр. Яхшылыкка өндәүче хакында Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

***«Иманлы ирләр белән иманлы хатыннарның берәүләре – икенчеләренең вәлиләре. Алар игелеккә әмер итәләр, тыелганнардан тыялар...»***

*«Әт-Тәүбә», 9:71*

Әмма ярамаган эш белән әмер итү икейөзлеләр галәмәтеннәндер. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

***«Монафикъ ирләр белән монафикъ хатыннар – икесе бер*** *[кыяфәт белән дә, күңелләре белән дә]*. ***Алар*** *[Пәйгамбәрне инкяр итү кебек акыл һәм дин ягыннан харам кылынган]* ***тыелганны әмер итәләр,*** *[шәһадәт кәлимәсе кебек акыл һәм шәригать ягыннан кабул ителгән]* ***игелектән тыялар...»***

*«Әт-Тәүбә», 9:67*

**«Тәнбиһүл гафилин»** китабыннан

# ӘНИЕМ ДӘРЕСЛӘРЕ


Фото: авторның шәхси архивыннан

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Мәктәпкә җыенып чыгып китәр алдыннан, һәркөнне диярлек, безне озатып калганда да киңәшләрен бирә иде:

– үз мәктәбеңдәге укучылар белән туганнарча йомшак мөгамәләдә бул, безгә сүз тидерерлек булмасын;

– укытучылар, мәктәп хезмәткәрләре – беренче ярдәмчеләрегез; сезнең өстә остазлар хакы зур, алар нәрсә кушса, җиренә җиткереп башкарыгыз, карышмагыз, тыйганнарыннан тыелыгыз, гөнаһларның кая илтәчәген беләсез;

– дәресләрдә сөйләшеп утырмагыз; тәнәфесләрдә әдәпле булыгыз, тавышыгызны күтәрмичә генә сөйләшегез; алдашмагыз, гайбәт тә сөйләмәгез;

– укытучылар янында түбәнчелекле булыгыз, аларны яратыгыз; алар сезне без ата-аналарыгыз кебек яраталар, белем бирәләр; шуңа күрә, иң элек, ата-анага кадәр остазларга дога кылына, онытмагыз; исән-сау кайтыгыз…

Менә шулай көн саен кабатланыр иде. Хәзер дә шулай озатабызмы балаларыбызны? Сорау арты сорау туа… Әниебезнең үгет-вәгазе моның белән генә бетми. Урамга чыгарга туры килсә: «Карагыз аны, балалар, безне оятлы итә күрмәгез. Күршеләрнең койма ярыкларыннан, ачык капка-ишекләреннән карап йөри күрмәгез! Бу гамәл белән үзеңне түбән тәгәрәтәсең, абруеңны, ягъни, дәрәҗәңне төшерәсең. Күршеләр белән исәнләшә торган булыгыз, хәлләрен сорашыгыз, берәр йомышлары булса, үтәргә тырышыгыз. Әҗер-саваплы булырсыз, иншәАллаһ.

Ә ялкаулардан, гайбәтчеләрдән ераграк йөрегез, алар сезгә дус түгел, нәселгә тап төшә күрмәсен, саграк булыгыз», – дип әйтә.

Кунаклар килсә дә, җаен чыгарып, берничә җөмлә булса да әйтеп куяр: «Балалар, туган-тумача да якын кешеләр. Аларны хөрмәтләп каршыларга һәм озатырга тиешлебез. Хәер, әдәп кагыйдәләрен үзегез дә беләсез, өйрәтеп торасы юк, болай гына әйтүем. Аллаһы Тәгалә рәхмәтеннән ташламасын, тәртипле булыгыз. Тәртибегез булса, бәхетегез дә булыр, иншәАллаһ», – дип, дога укып, битен сыпырыр иде. Нинди дога укыган, кызганыч, ул чакта соралмаган…

«Игелекне тиешле урыннарда кылырга тырышыгыз! Коръәндә «Мөэминнәр – бер-берсенә кардәшләр», диелгәнен онытмагыз».

Шул ук вакытта хәдисләр дә ятлатыр иде.

Бер-берегездән көнләшмәгез, бер-берегезне күрәлмаучанлык хисләре сакламагыз, тарткалашучыларга колак салмагыз, үз-үзен генә сөюче Карун һәм байлык җыючы булмагыз! Башка кешеләрнең гаепләрен эзләмәгез, үзегез сатып алырга теләмәгән малның хакын күтәрмәгез, бер-берегезне ташлап китмәгез, бәхәсләшмәгез һәм сезнең арадан берәүнең килешүенә ризасызлыгыгызны белдермәгез. Аллаһының коллары, туганнар булыгыз! Мөселман – мөселманның туганы, ул аны кысрыкламый, ярдәмсез калдырмый һәм нәфрәт белән карамый. Үзенең бер хәдисендә сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзенә теләгән нәрсәләрне кардәшенә дә теләми торып, берегез дә мөэмин булмас», – дигән.

Әниебез үзе киртәләр чистартканда, мине киендереп, ятлаганны тавыкларга сөйләтер иде. Алар мине тыңламагач: «Гадәтсезләр, вәгазь дә тыңлый белмисез!» – дип елар идем. Әниебез: «Елама, кызым, елама! Алар сиңа рәхмәт әйттеләр бит. Барысы да: «кыткытыйк» диделәр, аларның сөйләшүләре шулай, кызым, тагын сөйлә, сөйлә, кызым!» – дияр иде. Ул чагында миңа ничә яшь булгандыр, белмим, өстемдәге әти телогрейкасының җиргә тигәне исемдә калган…

…Бу китапны кулында тотучы, аны укучы хөрмәтле әти-әниләр, әби-бабайлар! Кирәк булганда, сез дә «Әнием дәресләре»н (мөмкин булса, минекеләрен дә кушып) каникулларга кайтучы оныкларыгызга, вәгазь урынына сөйли, аңлата аласыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләре Кыямәт көненә кадәр искерми бит! Олы юлга, бәхетле тормыш юлына чыгучыларга уңышлар, эш-гамәлләрен һәрдаим Аллаһы исеме белән башлауларын телик.

* * *

***Кеше картайган саен, бала вакыты, яшьлеге искә төшә, дигәнне барыбыз да белә белүен, шулай да үзен «карт кеше» дип, беребезнең дә әйтәсе килми – «олыгайдык» кына, дибез. Шәхсән, мин үзем: «Без картаймадык, туздык кына», – дип әйтәм. Күңел дигәнең бер дә картаймый бит. Әллә кайларга барып та кайта, эшләп, ярдәм итеп тә куя – барысын да булдыра, барысына да җитешә. Йокларга ятса да йоклап китә алмый әле. Әллә ниләр исенә төшә. Кемгә нәрсә, ә минем хәтергә һәрвакыт диярлек «Әнием вәгазьләре» килә. Онытылмыйлар да бит. Аның үз сөйләм ысуллары булган, күрәсең. Ул бервакытта да: «Алай ит, болай ит», – дип әйтмәс иде. Җәһәннәм белән дә куркытмады. Сайлау иреге бирде. Җае, вакыты белән, сүз арасында, яисә эш арасында берәр нәрсә аңлатып алыр иде. Түбәгә яки күккә карар иде дә: «И-и, балалар, барачак җиребез дә бар бит әле. Без бу дөньяда вакытлыча гына, кунак кына бит. Безнең бу матур дөньяда ничек яшәвебезгә карап, яхшы, мәрхәмәтле, әдәп-тәртипле, олыларны хөрмәтләп, гамәл-гыйбадәт белән яшәдекме, әллә яман, начар, гадәтсез, тәртипсез, ата-ана сүзен тыңламыйча, олылар сүзенә колак салмыйча яшәдекме – барысы да үлчәүгә салыначак», – дип сөйләп китәр иде…***

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Сәйдә абыстай Аппакованың**
«Тузмас бүләк» китабыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 06 (335) июнь, 2023 | зөлкагъдә–зөлхиҗҗә, 1444

# Сөннәтче бабай


Фотоның авторы: Ravil Sayfullin / shutterstock.com

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Арканың туңуы шул фикергә куәт бирде. Ул минут саен куәтләнә, «өйләнергә кирәк, өйләнергә кирәк», дип, уйлый башлады. Бик озак йоклый алмаенча уйлап торганның соңында, ул өйләнү фикеренә килде. Килде генә түгел, шул уйдан аерыла алмады. Ул, бер күрше малаенда күргән уенчыкны аталарыннан таптыра торган тирес бала кеби, шул уе берлән бөтенләй томаланды. Ул шул карардан соң яшәреп киткән кеби булды, аның искедәге киткән яшьлек көчләре кайткан кеби булды. Ул, урынына ятып, шул өйләнүләрне уйлый башлады. Үзенең әүвәлге өйләнүе, бикәчкә билбавының очын яшереп баруы, ишек бавына кызыл яулык бирүләре, җилән ябынган яшь бикәч берлән бергә ашка йөрүләре, туйлары, уенналары – һәммәсе бөтен вакларына кадәр күз алдыннан үтте. Ул тагы шунларның ләззәтен яңартып ләззәтләнде. Шул вакыттагы шатлыкларны хәтердән үткәреп, тагы рәхәтләнде. Менә ул тагы өйләнә, тагы аңар шул вакыттагы кеби кызык, күңелле була...

Ул, шул уй берлән җанланып, аркасы туңганын да хәтереннән чыгарып, вакытыннан иртә тәһарәт алып, намазга китте. Намаздан соң хәзрәт берлән сөйли-сөйли, хәзрәтләргә кадәр барып җитте. Чәй янында да шул сүздән туктамады. Хәзрәткә, абыстайга элгәре шул яше онытылган бабайның «өйләнәм» дип йөрүе көлке кеби тоелса да, Сөннәтче бабайның шул уй берлән саташканын күреп, каршы килүдә мәгънә юклыгын сизеп, яткан ягына сыйпарга тотындылар. Сөннәтче бабай, тәмам яшьләр кеби, авылдагы тол хатыннарны санарга тотынды. Бик файдалы, кыйммәтле кияү кеби, әллә никадәр тол хатыннарны яратмаенча үтеп китүе хәзрәт берлән абыстайның элгәре бераз исен дә китәрде. «Әллә гакылдан бераз яздымы?» – дигән фикергә дә төшерде. Ләкин башка хәрәкәтләре берлән бик гакыллы күренүе тагы анларны ул фикердән кайтарды. Сөннәтче бабай элгәре яучы булырга хәзрәтне яисә остазбикәне кушса да, бабайның күңеле бик югарыдан булганга, төрле хәйләләр табып, хәтта хәзрәт, иске әүлияларның үзләре өчен үзләре яучы булуларын сөйләп, үзенә баруны мәслихәт итте.

Бабай да, шул сүзне колагына элеп, белгән догаларын укып, күңеленә иң яраган иске мөәззин хатынына таба китте. Мөәззин хатыны абыстайның җиткән угыллары барлыгын да хәтеренә китермәенчә, мөәззин хатынының кияүгә барырга теләү-теләмәвен дә уйламаенча, туп-тугъры барып керде. Сөннәтче бабайны күргәч тә, мөәззин хатынының угылларының угыллары чыр-чыр килеп: «Кисә, кисә!» – дип качыштылар. Анлар артыннан кызлары да: «Кисә, кисә!» – дип почмакларга постылар. Мөәззин хатынының ялгыз гына калуын ганимәт белеп, Сөннәтче бабай тугърыдан-тугъры сүз салды. Карт остазбикә, элгәре исе китсә дә, Сөннәтче бабайны азрак гакылга җиңеләйгәндер ахры дип: «Утыр, утыр», – дип, сүзне башкага борырга теләде. Ләкин карт һаман үз сүзеннән кайтмаганга, «Әлхәмделилла, фәкыйрь түгелмен: арышым да бар, кәҗәм дә бик сөтле, бу ел сөннәт тә шактый күп», – дип, үзенең яхшы якларын сөйләп торганга, моның чынлап йөрүен аңлады һәм дә: «Рәхмәт!» – диде дә, ничек иттереп — бабаймы, әллә башкачамы әйтергә аптырап торып:

– Минем ул фикерем юк. Ирем мәрхүмгә вәгъдә бирдем. Балаларым да үсте. Менә шуларның балаларын тәрбия кылып гомер үткәрәм инде, – диде.

Сөннәтче бабай тагы үзенең Сәлман Фарси нәселеннән икәнен дә сөйләнсә дә, ул да тәэсир итмәде. Сөннәтче бабай, ясалган чәйне дә эчмәенчә, чыгып китте. Чыккан вакытта күңелендә бер төрле хурлану, ачу килү хисе булса да, шул остазбикәнең сүз кайтаруы Сөннәтче бабайның бәгъзе планнарын бозса да, ул, урамда уйлый-уйлый, ул фикер берлән да килешеп, түбән очта тегермәнче Фәхринең хатынына китте. Илле-илле бишләрдәге тегермәнче хатынының йортта чебешләр ашаткан җиренә тугъры килеп, хәләхваль сорашып, янына утырды; сүзне бик озаклап, читтән китереп тормаенча, тугърыдан-тугъры:

– Миңлесафа, мин сиңа яучылыкка килдем, – диде.

Шул сүзне ишеткәндә теге хатынның тавыклар, әтәчләрне куарга тоткан чыбыгы кулыннан төште. Шуны гына көтеп торган тавыклар, әтәчләр ябырылып алып, чебешләрнең азыгыны ашарга тотындылар. Теге, аптырап-катып торганның соңында, бабайның туктамый сөйләгән сүзләреннән элгәре аның җиңеләюенә хөкем итте. Бара-тора ул фикердән дә кайтты; ләкин ни дип җавап бирергә дә, ничек кайтарып җибәрергә дә сүз таба алмады. Уйлый төшәргә вакыт күбрәк ясар өчен: «Утыр, хәзер киләм», – дип, лапас астына җәйгән урынга күрсәтте; үзе базга төшеп, каймаклы катык алып чыгып, бабайның алдына куйды. Бабайның ашый-ашый сүзендә дәвам иткәнен дә күреп, карчык ничек шул ямьсез сүзне бетерергә юл эзләргә тотынды. Ул, мөәззин хатыны кеби:

– Угылым, кызым җиткән; ир тәрбия кылырлык хәлем юк, – диде.

Сөннәтче бабай моңар тагы, анда тормыш тормыш түгел — оҗмах икәнлегене сөйләсә дә, ахырдан гына үзенең Сәлман Фарси нәселеннән икәнлеген аңлатып, кыямәт көне Сәлман Фарсиның шәфагате берлән оҗмахка керү мәгълүм икәнлегене белдерсә дә, карчык әйткән сүзеннән кайтмады.

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Гаяз Исхакый** әсәреннән

### ДҮШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20, 17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40, 17:30** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55, 17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10, 18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**9:35, 18:25** «Фикер» 16+
**10:20, 19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45, 19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00, 19:55** «Дин турында» 12+
**11:30, 20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40, 20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05, 21:00** «Чудеса сотворения» 12+
**12:20, 21:15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:35, 21:30** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**13:10, 22:05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13:25, 22:20** «Узнаем у имама» 12+
**14:10** «Разговоры о важном» 12+
**14:15, 23:05** «Алифба» 12+
**14:35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00, 23:25** Документальные фильмы 12+
**15:35** «Тайна» 12+
**15:55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16:15** «Рухуль Байан» 12+
**16:20** «Ислам сегодня» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

### СИШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:30, 17:25** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**08:45, 17:40** «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» 12+
**09:00, 17:50** «Рисәлә» 12+
**09:15, 18:05** «Миллият сүзлеге» 12+
**09:35, 18:25** «Рухел Бәйан» 12+
**09:45, 18:35** «Татарлар тарихы» 12+
**10:30, 19:25** «Тәмле булсын» 12+
**10:50, 19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:40, 20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05, 21:00** «Азбука Ислама» 12+
**12:30, 21:25** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**13:05, 22:00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13:25, 22:20** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**14:00, 22:55** «Узнаем у имама» 12+
**14:45, 23:40** «Халид бин Валид» 12+
**15:40** «Познай свою религию» 12+
**16:00** «Ислам сегодня» 12+
**16:40, 00:35** «Поучительные истории» 12+
**16:45, 00:40** «Хафтияк Шариф» 12+
**17:00** «Мәслихәт» 12+
**20:35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

### ЧӘРШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20, 17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55, 17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10, 18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**9:35, 18:25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10:20, 19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45, 19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00, 19:55** «Дин турында» 12+
**11:30, 20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40, 20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05, 21:00** «Вера в предопределение» 12+
**12:15, 21:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:30, 21:25** «Онлайн медресе: Таджвид» 12+
**12:55** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**13:30, 22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:20, 21:50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14:35, 22:55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00, 23:20** Документальные фильмы (природа) 12+
**15:35, 23:55** «Тайна» 12+
**15:55, 00:15** «Голос разума» 12+
**16:30, 00:50** «Рухуль Байан» 12+
**16:35** «История ислама в России» 12+
**17:30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

### ПӘНҖЕШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20, 17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40, 17:30** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55, 17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10, 18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**9:35, 18:25** «Фикер» 16+
**10:20, 19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45, 19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00, 19:55** «Дин турында» 12+
**11:30, 20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40, 20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05, 21:00** «Чудеса сотворения» 12+
**12:20, 21:15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:35, 21:30** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**13:10, 22:05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13:25, 22:20** «Узнаем у имама» 12+
**14:10** «Разговоры о важном» 12+
**14:15, 23:05** «Алифба» 12+
**14:35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00, 23:25** Документальные фильмы 12+
**15:35** «Тайна» 12+
**15:55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16:15** «Рухуль Байан» 12+
**16:20** «Ислам сегодня» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

### ҖОМГА

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:30, 17:25** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**08:45, 17:40** «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» 12+
**09:00, 17:50** «Рисәлә» 12+
**09:15, 18:05** «Миллият сүзлеге» 12+
**09:35, 18:25** «Рухел Бәйан» 12+
**09:45, 18:35** «Татарлар тарихы» 12+
**10:30, 19:25** «Тәмле булсын» 12+
**10:50, 19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:40, 20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05, 21:00** «Азбука Ислама» 12+
**12:30, 21:25** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**13:05, 22:00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13:25, 22:20** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**14:00, 22:55** «Узнаем у имама» 12+
**14:45, 23:40** «Халид бин Валид» 12+
**15:40** «Познай свою религию» 12+
**16:00** «Ислам сегодня» 12+
**16:40, 00:35** «Поучительные истории» 12+
**16:45, 00:40** «Хафтияк Шариф» 12+
**17:00** «Мәслихәт» 12+
**20:35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

### ШИМБӘ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20, 17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55, 17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10, 18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**9:35, 18:25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10:20, 19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45, 19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00, 19:55** «Дин турында» 12+
**11:30, 20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40, 20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05, 21:00** «Вера в предопределение» 12+
**12:15, 21:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:30, 21:25** «Онлайн медресе: Таджвид» 12+
**12:55** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**13:30, 22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:20** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14:35, 22:55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00, 23:20** Документальные фильмы 12+
**15:35, 23:55** «Тайна» 12+
**15:55, 00:15** «Голос разума» 12+
**16:30, 00:50** «Рухуль Байан» 12+
**16:35** «История ислама в России» 12+
**17:30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**21:50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

### ЯКШӘМБЕ

**07:00** «Минбар» 12+
**07:35, 17:25** «Шифа» 12+
**08:10, 18:00** «Фикер» 12+
**09:00, 18:50** «Дин турында» 12+
**09:35, 19:20** «Мәслихәт» 12+
**10:00, 19:45** «Әхлак сабаклары» 12+
**10:10, 19:55** «Балам-багалмам» 12+
**10:35** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:25** «Намазга өйрәник» Ир-атлар өчен 12+
**11:45** «Миллият сүзлеге» 12+
**12:00** Азан 12+
**12:05** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**12:30, 21:25** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:45, 21:40** «Минбар. Истории» 12+
**13:15, 22:10** «Ислам сегодня» 12+
**13:55, 22:50** «Познай свою религию» 12+
**14:15, 23:10** «Узнаем у имама» 12+
**15:00, 23:55** Документальные фильмы 12+
**15:35, 00:30** «Медицина Пророка» 12+
**16:00** Короткометражный фильм 12+
**16:25** «40 хадисов 40 толкований» 12+
**17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**20:20** «Намазга өйрәник» хатын-кызлар өчен 12+
**20:40** «Тәмле булсын» 12+
**21:00** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+


## ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Юлдашева А. И., Ситдикова Г. Р.**
Логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Гарифуллин И. Ф.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** izdat@huzur.ru

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.


Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 000 данә. Заказ № 2590.
График буенча – 26 нчы июнь 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 175,38 сум. Индексы – П4333. Чыгу көне: 29 нчы июнь. Казан шәһәренең мәчетләрендә 29 нчы июнь көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## ИЮЛЬ 2023 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ, ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Шим | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 02 | Якш | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 03 | Дүш | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 04 | Сиш | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 11:47 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 |
| 05 | Чәрш | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 06 | Пәнҗ | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 07 | Җом | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |
| 08 | Шим | 01:09 | 01:39 | 03:09 | 11:48 | 12:00 | 17:32 | 20:26 | 21:56 |
| 09 | Якш | 01:11 | 01:41 | 03:11 | 11:48 | 12:00 | 17:32 | 20:25 | 21:55 |
| 10 | Дүш | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 11:48 | 12:00 | 17:32 | 20:24 | 21:54 |
| 11 | Сиш | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 11:49 | 12:00 | 17:31 | 20:23 | 21:53 |
| 12 | Чәрш | 01:14 | 01:44 | 03:14 | 11:49 | 12:00 | 17:31 | 20:22 | 21:52 |
| 13 | Пәнҗ | 01:16 | 01:46 | 03:16 | 11:49 | 12:00 | 17:30 | 20:21 | 21:51 |
| 14 | Җом | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 11:49 | 12:00 | 17:30 | 20:20 | 21:50 |
| 15 | Шим | 01:18 | 01:48 | 03:18 | 11:49 | 12:00 | 17:29 | 20:19 | 21:49 |
| 16 | Якш | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 11:49 | 12:00 | 17:28 | 20:17 | 21:47 |
| 17 | Дүш | 01:21 | 01:51 | 03:21 | 11:49 | 12:00 | 17:28 | 20:16 | 21:46 |
| 18 | Сиш | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 11:49 | 12:00 | 17:27 | 20:14 | 21:44 |
| 19 | Чәрш | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 11:49 | 12:00 | 17:26 | 20:13 | 21:43 |
| 20 | Пәнҗ | 01:26 | 01:56 | 03:26 | 11:49 | 12:00 | 17:25 | 20:12 | 21:42 |
| 21 | Җом | 01:28 | 01:58 | 03:28 | 11:49 | 12:00 | 17:25 | 20:10 | 21:40 |
| 22 | Шим | 01:29 | 01:59 | 03:29 | 11:49 | 12:00 | 17:24 | 20:08 | 21:38 |
| 23 | Якш | 01:31 | 02:01 | 03:31 | 11:50 | 12:00 | 17:23 | 20:07 | 21:37 |
| 24 | Дүш | 01:33 | 02:03 | 03:33 | 11:50 | 12:00 | 17:22 | 20:05 | 21:35 |
| 25 | Сиш | 01:34 | 02:04 | 03:34 | 11:50 | 12:00 | 17:21 | 20:03 | 21:33 |
| 26 | Чәрш | 01:36 | 02:06 | 03:36 | 11:50 | 12:00 | 17:20 | 20:02 | 21:32 |
| 27 | Пәнҗ | 01:38 | 02:08 | 03:38 | 11:50 | 12:00 | 17:19 | 20:00 | 21:30 |
| 28 | Җом | 01:40 | 02:10 | 03:40 | 11:50 | 12:00 | 17:18 | 19:58 | 21:28 |
| 29 | Шим | 01:42 | 02:12 | 03:42 | 11:50 | 12:00 | 17:17 | 19:56 | 21:26 |
| 30 | Якш | 01:43 | 02:13 | 03:43 | 11:49 | 12:00 | 17:16 | 19:54 | 21:24 |
| 31 | Дүш | 01:45 | 02:15 | 03:45 | 11:49 | 12:00 | 17:15 | 19:52 | 21:22 |

19 нчы июль – мөхәррам аеның беренче көне. 28 нче июль – Гашурә көне.